| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.06.20023 Казан ш. № 389-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында” 26.02.2021 № 116-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

Законнардагы үзгәрешләр кертелүгә бәйле б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында” 26.02.2021 № 116-пр боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.03.2023 № 158-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәсенә кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 29 апреленнән соңгы хокук мөнәсәбәтләренә карый.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
________________№ _________
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында” 26.02.2021 № 116-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәсенә кертелә торган үзгәрешләр

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Конкурс дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын (алга таба – гражданлык хезмәте) биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның бу вазыйфаны биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдән һәм кандидатлар арасыннан гражданинны яки гражданлык хезмәткәрен тикшерү һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләүдән гыйбарәт.»;

1.7 пунктта:

өченче абзацта «кече вазыйфалары төркеменә» сүзләрен «вазыйфаларның кече төркеменә» сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«федераль законнар белән каралган башка очракларда»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Гражданин (граждан хезмәткәре) түбәндәге очракларда конкурста катнашырга кертелми:

а) профессиональ белем дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте стажы яки белгечлек буенча эше, әзерлек юнәлеше квалификацион таләпләргә туры килмәү сәбәпле;

б) белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекнең һәм әзерлек юнәлешенең эреләндерелгән төркемнәренә), өстәмә һөнәри кабат әзерлек һөнәри программаларны үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификацияләргә (гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә квалификацион таләпләргә шундый таләпләр каралган булса) туры килмәү сәбәпле;

в) гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтүгә һәм Россия Федерациянең дәүләт гражданлык хезмәте турында законнарында билгеләнгән чикләүләр белән бәйле»;

3.4 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем алу турында һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, үз ихтыяры буенча, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;»;

4.1 пунктта «һөнәри һәм шәхси сыйфатларын» сүзләрен «профессиональ дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын» сүзләре белән алмаштырырга;

4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданлык хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфаларына мөнәсәбәтле министр карары буенча гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламантларында белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекнең һәм әзерлек юнәлешенең эреләндерелгән төркемнәренә), өстәмә һөнәри кабат әзерлек һөнәри программаларны үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификацияләргә квалификацион таләпләр куела ала.»;

4.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, гражданлык хезмәте яки белгечлеге буенча эшләү стажына, әзерлек юнәлешенә, һөнәри дәрәҗәсенә квалификация таләпләренә, шулай ук, министрның тиеше карары булса – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлек һәм әзерлек юнәлешенең эреләндерелгән төркемнәренә) өстәмә һөнәри кабат әзерлек һөнәри программаларны үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификацияләргә туры килүен тикшерә.»;

4.11 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү;»;

4.12 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Конкурсны уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, гражданлык хезмәтен яки бүтән дәүләт хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү алымнарын үз эченә алган шәхси әңгәмәләр, анкеталар, төркем белән дискуссияләр уздыру, реферат яздыру яки кандидат дәгъва иткшн граждан хезмәте вакантлы вазыйфасның вазыйфаи бурычларына бәйле тестларны ысулларын үз эченә алган конкурс процедуралары нигезендә бәяли. Конкурс үткәрелгән вазифаларның төркеменә һәм категориясенә карап, төрле ысуллар кулланыла ала. Конкурс уздырылган вазыйфа төркеменә һәм

категориясенә бәйле рәвештә төрле ысуллар кулланыла ала. Шул ук вакытта тест уздыру һәм кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр бөтен кандидатлар өчен мәҗбүри санала.»;

4.12.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тест уздыру Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты раслаган гражданлык хезмәткәрләренә һәм гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва иткән гражданнарга тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла.»;

4.16 пунктның беренче абзацын «гражданлык хезмәте» сүзләреннән соң «профессиональ дәрәҗәсе» сүзләре белән тулыландырырга.